МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__25.11.2021_____ г. Казань № __под-1536/21_____

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 1 июнендәге 6536/15 номерлы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы «Татарстан Республикасы министрлыгы, Дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 8 ноябрендәге 1058 номерлы «Татарстан Республикасы министрлыгы, Дәүләт комитеты, ведомство каршындагы Иҗтимагый совет турындагы типлаштырылган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында " карары нигезендә к а р а р б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 1 июнендәге 6536/15 номерлы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында» боерыгы белән расланган (14.09.2015 елның № под-9277/15, 06.06.2016 елның № под-1115/16, 17.01.2018 елның № под-69/18, 20.08.2018 елның № под-1226/18, 23.05.2019 елның № под-845/19 боерыкларында булган үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктында:

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык эшчәнлегенә җәмәгать күзәтүен гамәлгә ашыру»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Иҗтимагый советның бурычлары:

мәгариф һәм фән өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерүдә катнашу;

Министрлык карарларын кабул иткәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең мәгълүматлылыгын арттыру;

җәмгыятьтә коррупцион тәртипкә түземсезлек булдыру.»;

2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.5 пунктын өстәргә:

«2.5. Әлеге максатларга ирешү һәм куелган бурычларны хәл итү өчен Иҗтимагый совет:

мәгариф һәм фән өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

коррупциягә каршы тору эшчәнлегендә катнаша;

2014 елның 21 июлендәге № 212-ФЗ «Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» номерлы Федераль закон нигезендә Министрлык тарафыннан эшләнелә торган норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрүне оештыра. Әлеге документлар бу орган каршындагы Иҗтимагый совет утырышында алдан фикер алышудан башка кабул ителә алмый;

Министрлык тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты мониторингында катнаша;

дәүләт сатып алуларының нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнаша;

дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләрен аттестацияләү өчен аттестация комиссияләре эшендә катнаша.»;

3.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре срогы яңа оешкан Иҗтимагый Совет составының беренче утырышы уздырылган көннән алып өч ел тәшкил итә.»;

3.6-3.8 пунктларын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре Министрлык боерыгы нигезендә, Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме белән түбәндәге очракларда туктатыла:

аңа Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаеп белдерүләр;

аңа административ формада ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә административ җәза билгеләү;

аның дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органына депутатлыкка кандидат, җирле үзидарә органында сайланулы вазыйфага кандидат, ышанычлы зат яисә сәяси партия кандидатының вәкаләтле вәкиле буларак, шулай ук аны Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кергән очракта кандидат булып теркәлүе;

әлеге нигезләмәнең 6.6 пунктында каралган сәбәпләрнең булуы.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

аның вәкаләтләре вакыты тәмамлануга;

аның Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза бирүе;

аның сәламәтлеге буенча Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмавы;

аңа карата чыгарылган суд карары законлы көченә керүе;

закон көченә кергән суд карары нигезендә аны эшкә яраксыз яисә билгесез дип тану;

этик нормаларын тупас бозу – Иҗтимагый совет әгъзалары санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Иҗтимагый совет утырышлары эшендә җитди сәбәпсез системалы (өч тапкырдан артык) катнашмау;

Иҗтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасары йөкләмәләрен нигезле сәбәпсез системалы рәвештә үтәмәү (ике тапкырдан артык);

аны Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую;

чит ил гражданлыгы булу;

Россия Федерациясе гражданлыгын туктату;

Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату Иҗтимагый совет әгъзасы язма гаризасы яисә Иҗтимагый совет рәисе биргән гариза нигезендә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктында каралган шартлар ачыкланган очракта, Министрлык боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы Иҗтимагый совет рәисенә әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктындагы дүртенче, бишенче, унынчы – уникенче абзацларында каралган шартлар турында хәбәр итәргә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлектә 6-нчы бүлекне өстәргә:

«6. Иҗтимагый советта мәнфәгатьләр каршылыгы

6.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы - Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси кызыксынуы аның үз вазыйфаларын тиешенчә, объектив һәм гадел үтәүгә (вәкаләтләрне гамәлгә ашыру) йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган һәм Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси кызыксынуы белән Иҗтимагый совет әгъзасының максатлары, бурычлары арасында каршылык барлыкка килергә мөмкин булган хәл.

6.2. Иҗтимагый совет әгъзасының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның дөреслегенә һәм гаделлегенә йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынуы астында, Иҗтимагый совет әгъзасы тарафыннан акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәт хокуклары, үзе яки өченче затлар өчен хезмәт күрсәтү рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге бәяләнә.

6.3. Иҗтимагый совет әгъзасы мәнфәгатьләр каршылыгы яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында белүгә үк, Иҗтимагый совет рәисе һәм министрга язма форма хәбәр бирергә тиеш. Иҗтимагый совет рәисе бу хакта Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

Иҗтимагый совет рәисе министр һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына мәнфәгатьләр каршылыгы яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында, бу хакта аңа билгеле булганча, язма рәвештә хәбәр итәргә бурычлы.

6.4. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында мәгълүм булуга, Иҗтимагый совет рәисе яисә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату яисә туктату турында министрга тәкъдим кертү юлы белән чаралар күрергә тиеш.

6.5. Иҗтимагый совет рәисе яисә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы иҗтимагый Совет эшчәнлегендәге коррупциячел хәвеф-хәтәрләрне бәяли һәм Иҗтимагый совет әгъзаларының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашуына юл куймау максатларында аларны киметү буенча чаралар күрә.

Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүм булган Иҗтимагый совет рәисе өч эш көне дәвамында бу хакта министрның язма рәвешендә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый Палатасына хәбәр итә.

Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты турында белгән Иҗтимагый совет әгъзалары өч эш көне дәвамында бу хакта язма рәвештә Татарстан Республикасы Иҗтимагый Палатасына хәбәр итә.

6.6. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрына Иҗтимагый совет әгъзасының Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүмат алган очракта иҗтимагый совет эшендә катнашуын туктатып тору турында тәкъдим кертә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрының Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктатып тору турындагы карары Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш.

6.7. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә китерә торган шартлар бетмәсә яки Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты расланса, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрына Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турында тәкъдим кертә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрының Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турындагы карары Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш.

6.8. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә китерә торган шартлар бетерелгән (расланмаган) һәм (яки) Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты расланмаган очракта, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Татарстан Республикасы Мәгариф

һәм фән министрына Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен яңарту турында тәкъдим кертә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрының Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен яңадан торгызу турындагы карары Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш.».

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының юридик бүлегенә (Е.С.Борисова) боерык кабул ителгән көннән алып, 3 эш көне дәвамында аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары С.Р.Андреевка йөкләргә.

Министр И.Г.Һадиуллин